ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 158-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 158-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 562-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Җир кодексының**
**8 статьясына үзгәреш кертү турында**

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш), 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 75 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2026, № 2 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«8 статья. **Җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү**

1. Җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү федераль законнарда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, әлеге Кодекста һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләреннән тыш, бер категориядән

икенче категориягә күчерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләренә карата җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен, федераль милектәге җирләрдән тыш, бер категориядән икенче категориягә күчерү турындагы акт авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерүне күздә тоткан Татарстан Республикасы Законы нигезендә вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан кабул ителә.

4. Авыл хуҗалыгы җирләрен яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерүне күздә тота торган Татарстан Республикасы законы проекты, бәяләмә алу өчен, Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив - хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына җибәрелә һәм бер үк вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

2. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне башка категориягә күчерү турында һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составындагы җир кишәрлекләрен башка категориягә күчерү турында 2026 елның 1 мартына кадәр кергән үтенечнамәләр әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр билгеләнгән тәртиптә карала.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының
8 статьясына үзгәреш кертү турында»
Татарстан Республикасы закон проектына
АҢЛАТМА**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 1 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законга 2026 елның 1 мартыннан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне икенче категориягә күчерүнең яңа тәртибен кертүне күздә тота торган үзгәрешләр кертелде.

Күрсәтелгән көннән башлап авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне башка категориягә күчерү (алга таба – авыл хуҗалыгы җирләрен күчерү) турында карар кабул итү процедурасы түбәндәгеләрне күздә тота:

1) Россия Федерациясе субъекты башкарма органы тарафыннан авыл хуҗалыгы җирләрен башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамәне карау;

2) үтенечнамәне караудан баш тарту өчен нигезләр булмаганда Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына авыл хуҗалыгы җирләрен күчерү турында тәкъдим җибәрү;

3) тәкъдим белән килешкән очракта Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты тарафыннан Россия Федерациясе субъектының закон чыгару органына авыл хуҗалыгы җирләрен күчерүне күздә тота торган закон чыгару инициативасын җибәрү;

4) авыл хуҗалыгы җирләрен яисә мондый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен күчергән очракта күчерүне вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы белән 20 көн эчендә килештерү;

5) Россия Федерациясе субъектының закон чыгару органы тарафыннан авыл хуҗалыгы җирләрен күчерү турында закон кабул ителү;

6) күрсәтелгән закон нигезендә Россия Федерациясе субъектының башкарма органы тарафыннан авыл хуҗалыгы җирләрен күчерү турында акт кабул ителү.

Яңалыкларны чагылдыру максатында закон проектында Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына төзәтмә кертү карала. Аерым алганда, Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне яисә андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен, авыл хуҗалыгы җирләреннән тыш, бер категориядән икенче категориягә күчерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләнә. Авыл хуҗалыгы җирләрен күчерү турында актны кабул итү вәкаләте вәкаләтле органга - Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тапшырыла.

Авыл хуҗалыгы җирләрен күчерүне күздә тота торган Татарстан Республикасы законы проекты, бәяләмә алу өчен, Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына җибәрелә һәм бер үк вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелә дип билгеләнә.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының**
**8 статьясына үзгәреш кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларына үзгәрешләр кертүне таләп итә:

«Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 елның 25 октябрендәге 523 номерлы карар;

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 22 августындагы 407 номерлы карар.

Моннан тыш, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 29 декабрендәге 750-пр номерлы боерыгына төзәтмәләр кертү таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының**
**8 статьясына үзгәреш кертү турында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.